ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 27 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» 2007 елның 13 ноябрендәге 58-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 11; 2010, № 12 (II өлеш); 2014, № 4; 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 78 (I өлеш); 2023, № 56 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 статьяга түбәндәге эчтәлекле 7 өлеш өстәргә:
«7. Дәүләт мәгълүмат системаларындагы мәгълүматны «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясында билгеләнгән мәгълүматны яклау хакындагы таләпләргә туры килми торган башка мәгълүмат системаларына тапшыру рөхсәт ителми.»;

2) 12 статьяның 3 өлешендә «федераль законнар» сүзләреннән соң «һәм Россия Федерациясе Президенты актлары» сүзләрен өстәргә;

3) 15 статьяның 2 өлешендә «системаларындагы» сүзеннән соң «, дәүләт органнарының, дәүләт унитар предприятиеләренең, дәүләт учреждениеләренең башка мәгълүмат системаларындагы» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе                                        Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
АДМИНИСТРАЦИИ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2024 ел, 07 октябрь
№ 79-ТРЗ